КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 октябрь г.Казань № 1090

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 20 февраль, 80 нче; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 930 нчы; 2019 ел, 6 декабрь, 1119 нчы, 2019 ел, 30 декабрь, 1266 нчы, 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче, 2022 ел, 11 февраль, 111 нче, 2022 ел, 22 февраль, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының махсус сакланылучы табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертергә;

Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре турында белешмәләрне күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү хокукларын теркәү органына билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.»;

4 һәм 5 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин